Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы
Кощаково авыл җирлеге Советының алтынчы утырышы

Кощаково авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

29 декабрь, 2025 ел № 16

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кощаково авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кощаково авыл җирлеге башлыгы һәм муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү турында» 2021 елның 9 апрелендәге 24 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, Рәис урынбасарларының, аудиторларының, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына ярашлы рәвештә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кощаково авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кощаково авыл җирлеге башлыгы һәм муниципаль хезмәткәрләре хезмәтенә түләү турында» 2021 елның 9 апрелендәге 24 номерлы Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кощаково авыл җирлеге Советы карарына (Кощаково авыл җирлеге Советының 2022 елның 10 октябрендәге 62 номерлы, 2022 елның 29 декабрендәге 73 номерлы, 2024 елның 29 маендагы 115 номерлы, 2025 елның 31 гыйнварындагы 137 номерлы, 2025 елның 23 маендагы 144 номерлы карарлары белән расланган үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. пунктның 1.1 пунктчасында «25 091» санын «27 601» саннарына алмаштырырга.

1.2. пунктның 1.2 пунктчасында «15 389» санын «16 928» саннарына алмаштырырга.

2. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тиешле финанс елына җирле бюджетларда каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы
Кощаково авыл җирлеге башлыгы З.Н. Саттарова